ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЕГОРКИНО
АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 7 «23» декабрь 2019 ел

2020 елга Егоркино авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзаны үтәүче оешмалар исемлеген билгеләү турында

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 16.11.2012 ел, ПР-43-6 номерлы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының карарын үтәү йөзеннән (Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексына 2012 елның 8 июнендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә), мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатларында), административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә һәм законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендәге мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Егоркино авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Мәҗбүри яисә төзәтү эшләре рәвешендә хөкем ителгәннәргә җәзасын үтәү өчен мәҗбүри һәм төзәтү эшләре төрләрен түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Төзекләндерү: территорияне чистарту, яшелләндерү, җир эшләре, юлларны һәм тышкы төзекләндерүнең башка объектларын ремонтлау.

- Территорияләрне санитар чистарту.

- йөк төяү-бушату эшләре.

Башлангыч һәм һөнәри әзерлек таләп итмәгән хезмәт эшчәнлегенең башка һәркем файдалана алырлык төрләре, җинаять башкарма инспекциясе белән килештереп.

2. 2020 елга Егоркино авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри яки төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәтү өчен объект итеп җинаятьләрне үтәтү инспекциясе белән килештерү буенча Егоркино авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

3. "Егоркино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаны үтәтү объекты итеп Егоркино авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

4. Әлеге карарны, төзәтү эшләренә хөкем ителгән һәм Егоркино авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд карарлары үтәлешен тәэмин итү

өчен, Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат муниципальара филиалы ФКУнә җибәрергә.

5. Карарны «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта һәм мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.С.Яковлева